**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в статью $2^1$ Закона Республики Татарстан «О реализации государственной политики в области содействия занятости населения в Республике Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 апреля 2022 года

**Статья 1**

Внести в статью $2^1$ Закона Республики Татарстан от 19 июня 2006 года № 39-ЗРТ «О реализации государственной политики в области содействия занятости населения в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 6 (I часть); 2007, № 4; 2011, № 8 (I часть); 2012, № 12 (I часть); 2014, № 6 (II часть), № 12 (II часть); 2015, № 5, № 10 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 27 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 92 (часть I); 2020, № 1 (часть I), № 51 (часть I); 2021, № 93 (часть I) следующие изменения:

1) в пункте 1 части 3:

а) абзац третий признать утратившим силу;

б) в абзаце четвертом слова «и женщинам в период отпуска по уходу за ребенком до достижения им возраста трех лет, а также незанятым гражданам, которым в соответствии с законодательством Российской Федерации назначена страховая пенсия по старости и которые стремятся возобновить трудовую деятельность» исключить;

в) абзацы шестой и седьмой признать утратившими силу;

2) в абзаце первом части $3^1$ слова «в порядке и с учетом критериев отбора работодателей, подлежащих включению в государственную программу, которые устанавливаются Кабинетом Министров Республики Татарстан,» исключить;

3) часть $3^3$ изложить в следующей редакции:

«$3^{3}$. Кабинет Министров Республики Татарстан вправе:

1) устанавливать дополнительную финансовую поддержку безработным гражданам и членам их семей, переселяющимся для трудоустройства по направлению органов службы занятости в сельскую местность;

2) устанавливать порядок организации профессионального обучения или дополнительного профессионального образования женщин в период отпуска по уходу за ребенком до достижения им возраста трех лет, незанятых граждан, которым в соответствии с законодательством Российской Федерации назначена страховая пенсия по старости и которые стремятся возобновить трудовую деятельность;

3) устанавливать порядок предоставления финансовой поддержки женщинам в период отпуска по уходу за ребенком до достижения им возраста трех лет, незанятым гражданам, которым в соответствии с законодательством Российской Федерации назначена страховая пенсия по старости и которые стремятся возобновить трудовую деятельность, направленным органами службы занятости для прохождения профессионального обучения или получения дополнительного профессионального образования в другую местность, а также размеры указанной финансовой поддержки;

4) осуществлять разработку и реализацию мероприятий, направленных на создание условий для совмещения незанятыми многодетными родителями, родителями, воспитывающими детей-инвалидов, обязанностей по воспитанию детей с трудовой деятельностью.»;

4) часть 5 признать утратившей силу.

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
29 апреля 2022 года
№ 27-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 5, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 51 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 өлешнең 1 пунктында:
а) өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;
б) дүртенче абзацта «һәм өч яшькә кадәрге бала карау ялында булу чорында хатын-кызларга, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген торгызырга омтылган эш белән тәэмин ителмәгән гражданнарга» сүзләрен төшереп калдырырга;
в) алтынчы һәм җиденче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

2) $3^1$ өлешнең беренче абзацында «, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә һәм дәүләт программасына кертелергә тиешле эш бирүчеләрне сайлап алу критерийларын исәпкә алып,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) $3^3$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$3^3$. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты түбәндәгеләргә хокуклы:

1) эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен авыл җирлегенә күченүче эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына өстәмә финанс ярдәме билгеләргә;

2) өч яшькә кадәрге бала карау ялында булу чорында хатын-кызларны, Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген яңадан дәвам итәргә теләүче эш белән тәэмин ителмәгән гражданнарны һөнәри укытуны яисә аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру тәртибен билгеләргә;

3) өч яшькә кадәрге бала карау ялында булу чорында хатын-кызларга, Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген яңадан дәвам итәргә теләүче эш белән тәэмин ителмәгән гражданнарга, эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан һөнәри уку узу яисә өстәмә һөнәри белем алу өчен башка җиргә җибәрелгәндә, финанс ярдәме күрсәтү тәртибен, шулай ук күрсәтелгән финанс ярдәменең күләмнәрен билгеләргә;

4) эш белән тәэмин ителмәгән күпбалалы ата-аналарның, инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналарның балаларны тәрбияләү бурычларын хезмәт эшчәнлеге белән бергә алып баруы өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чараларны эшләргә һәм гамәлгә ашырырга.»;

4) 5 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *

Казан, Кремль
2022 ел, 29 апрель
№ 27-ТРЗ